МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

01.12.2020 г.Казань № 802-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 115-осн номерлы боерыгы белән расланган Әгерҗе урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 115-осн номерлы боерыгы (2020 елның 10 апрелендәге 292-осн номерлы боерык нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Әгерҗе урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентының 2.17 бүлегендәге 2.17.3 бүлекчәсенә үзгәреш кертеп, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Урманнарны торгызу кагыйдәләренең 12 пункты нигезендә урманнарны торгызганда утыртылган, мәйданнары урман урнашкан җирләргә кертелергә тиешле, Урманнарны торгызу кагыйдәләренең 1-40 кушымталарына кертелмәгән урман агач токымы үсентеләренә карата критерийлар һәм таләпләр урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларында билгеләнә.

17.1 нче таблица

Әгерҗе урманчылыгы урманнары урнашкан җирләргә кертелергә тиешле мәйданнардагы урман агач токымы үсентеләренә карата критерийлар һәм таләпләр

| Урман агач токымы атамасы | Яше, кимендә, ел | Төп токым агачлары саны, кимендә, 1 гектарга мең данә | Төп токым агачларының уртача биеклеге, кимендә, м |
|---|---|---|---|
| Гади өрәңге | 7 | 1,5 | 0,9 |
| Вак яфраклы юкә | 5 | 2,0 | 1,3 |
| Гади усак | 5 | 2,0 | 1,3 |
| Ак тирәк | 5 | 2,0 | 1,3 |
| Ланцетлы корычагач | 5 | 2,0 | 1,7». |

Министр Р.Ә.Кузюров